ГЛАВА
МУРАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
МӨРӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 октябрь, 2019 ел Мөрәле ав. № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районы Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2019 елның 21 октябренә 13 сәг 00 минутка Мөрәле ав., Үзәк ур, 70а йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***беренче этабын билгеләргә.***
2. 2019 елның 23 октябренә 15 сәг 30 минутка Мөрәле ав., Маршал Жуков ур., 1 нче йорт адресы буенча урнашкан Дубрава җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең административ бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***икенче этабын*** билгеләргә.
3. 2019 елның 25 октябренә 18 сәг 00 минутка Мөрәле ав., Үзәк ур., 45нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***өченче этабын*** билгеләргә.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны урыны буенча Мөрәле авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

а) авыл җирлеге территориясен төзеклэнләндерү:

-торак пунктның чүплекләре территорияләрен чистарту;

б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру

- Мөрәле авылында су насосын алыштыру , моның өчен материаллар сатып алу;

- Мөрәле авылында янгын гидрантларын урнаштыру , моның өчен материаллар сатып алу;

в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Мөрәле авылында юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;

- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

« РИЗА» «КАРШЫ»

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Республикасы Кайбыч муниципаль районының
Мөрәле авыл җирлеге Башлыгы Р.Р.Зиннатуллин

Совет Муралинского сельского поселения Мөрәле авыл җирлеге Советы ИНН 1621001143